КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 декабрь г.Казань № 1199

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 862 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 862 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 март, 291 нче; 2022 ел, 14 сентябрь, 1000 нче; 2022 ел, 16 декабрь, 1358 нче; 2023 ел, 20 март, 280 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында»;

1.2 пунктка татар текстында «2024 елда» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2024 елда устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе»;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм 2024 елда устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – предприятие, субсидия) бирү максатын, шартларын һәм тәртибен билгели.»;

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Субсидия предприятиегә махсус һәм коммуналь техника, машиналар һәм җайланмалар, хәрәкәтчән состав (автобуслар) сатып алу чыгымнарын финанс белән тәэмин итү максатларында устав фондын арттыруга бирелә.»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак 2024 елда субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык).»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлеше – махсус һәм коммуналь техника, машиналар һәм җиһазлар, хәрәкәтчән состав (автобуслар) сатып алу.»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.1 пунктта:

өченче абзацта «5нче» сүзләрен «икенче» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта татар текстында «машиналар һәм җиһазлар» сүзләреннән соң «, хәрәкәтчән состав (автобуслар)» сүзләрен өстәргә;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлап алуны үткәрү чорында сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләре, әгәр дә сорату Министрлыкка заявкалар бирү срогы тәмамлану датасына кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча керсә, Министрлык тарафыннан предприятиеләргә Министрлыкка тиешле сорату кергән датадан бер эш көне эчендә

электрон документ рәвешендә кергән соратуда күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яки язма рәвештә кергән соратуда күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә бирелә.»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Предприятие сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1енә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки предприятиенең баш хисапчысы турында мәгълүматлар булмау;

үзгәртеп оештыру (Җәмгыятькә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, Җәмгыятьнең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмау;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган

террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый.»;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Сайлап алуда катнашу өчен предприятие Министрлыкка әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча, түбәндәге документларны теркәп, гариза бирә:

предприятие җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат тарафыннан расланган предприятиенең гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга барлык үзгәрешләрне кертү турында документлар күчермәләре (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә күчермәсен теркәп);

предприятиенең мөһере белән расланган юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яисә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазе күчермәсе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан заявкалар кабул ителә башланганга кадәр өч айдан да иртәрәк бирелмәгән предприятие турында мәгълүмат белән өземтә күчермәсе;

бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре түләү бурычы булмавын яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе;

Министрлык тарафыннан бердәм порталда һәм рәсми сайтта предприятие турында, предприятие бирә торган заявка турында мәгълүмат, сайлап алуга бәйле предприятие турында башка мәгълүмат хакында басылып чыксын (урнаштырылсын) өчен предприятиенең ризалыгы;

җитәкче яисә предприятие исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат һәм предприятиенең баш бухгалтеры тарафыннан имза куелган әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә предприятиенең туры килүен раслый торган мәгълүмати белешмә кәгазе.

Әлеге пунктның өченче – бишенче абзацларында күрсәтелгән документлар предприятие тарафыннан тапшырылмаган очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар бер папка (том) итеп тегелгән, һәр бите номерланган, предприятие җитәкчесенең яки тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле затның (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) имзасы куелган һәм мөһер сугылган булырга тиеш.

Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр (предприятие җитәкчесенең үз кулы белән куелган имзасы белән расланган һәм мөһер сугылган төзәтмәләрдән тыш) рөхсәт ителми.

Министрлыкка заявкалар кабул итү вакыты башланганга кадәр яки заявкалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң (шул исәптән почта элемтәсе оешмалары аша) килгән заявкалар теркәлми, карап тикшерелми, бу турыда мондый заявкалар кергән көннән ике эш көне эчендә Министрлык электрон почта аша предприятиегә хәбәр итә һәм аңа заявканы почта элемтәсе оешмасы аша кире кайтара.»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Предприятие заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда предприятие заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яки заявканы кире алу предприятие тарафыннан әлеге Тәртиптә билгеләнгән заявка формалаштыру тәртибендәге кебек тртиптә предприятие тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

2.8 пунктта:

алтынчы абзацта «өч көн» сүзләрен «ике көн» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «биш эш көне» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алыштырырга;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

Министрлык тарафыннан әлеге Тәртипнең 5.2 пунктында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда алардан файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә финанс белән тәэмин итү чыганагы хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге карала торган шарт;

субсидия алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә грант алучының ризалыгы;

субсидия алучы, шулай ук субсидия алучылар белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр

җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешә алмаганда килешүне өзү хакында шарт;

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә субсидия алучы үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

Килешү Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә төзелә.

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Субсидия бирү нәтиҗәсе – предприятиенең устав капиталын 2025 елның 31 декабренә карата субсидия акчасыннан файдаланып сатып алынган махсус һәм коммуналь техника, машиналар һәм җиһазлар, хәрәкәтчән состав (автобуслар) кыйммәтеннән ким булмаган суммага арттыру.»;

3.5 пунктта:

беренче абзацта «җиһазлар» сүзеннән соң «, хәрәкәтчән состав (автобуслар)» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «җиһазлар» сүзеннән соң «, хәрәкәтчән состав (автобуслар)» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «җиһазлар» сүзеннән соң «, хәрәкәтчән состав (автобуслар)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 3.6 пункт өстәргә:

«3.6. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 2.4 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.»;

$5.1^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$5.1^1$. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечено ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан

расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.»;

5.2 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5.6 пункт өстәргә:

«5.6. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»

әлеге Тәртипнең кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин

2024 елда устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 25 декабрь, 1199 нчы
карары редакциясендә)

Форма

2024 елда устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирүгә сайлап алуда катнашуга тәкъдим (заявка)

1. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең тулы исеме: ______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

2. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең юридик адресы: ______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
телефоны: _________________ e-mail: _____________________________________

3. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе җитәкчесенең (вәкаләтле затның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазифасы: __________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
телефоны: _________________ e-mail: _____________________________________

4. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләре турында мәгълүмат: _________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

5. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең реквизитлары:

салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры: _________________________________

исәпкә куелу сәбәбенең коды: ___________________________________________

төп дәүләт теркәү номеры: ______________________________________________

исәп-хисап счеты: ______________________________________________________

банкның исеме һәм урнашу урыны: _______________________________________

корреспондент счеты: ___________________________________________________

банк идентификация коды: ______________________________________________

6. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе:

бердәй салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджет-ларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлары юк йә

бурыч Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки оешманың баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмау;

үзгәртеп оештыру (Җәмгыятькә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, Җәмгыятьнең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмау;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан

Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 862 нче карары белән расланган 2024 елда устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 1.2 пунктында билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый»;

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара, дип раслыйм.

7. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://minstroy.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе турында, Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүмат, сайлап алу үткәрүгә бәйле Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык бирәм.

Татарстан Республикасы
дәүләт унитар предприятиесе
җитәкчесе (вәкаләтле зат) ________________ ____________ ______________________
(вазыйфа) (имза) (имзаны таркатып язу)

Башкаручы ________________________ ____________ ____________________ ______________
(вазыйфа) (имза) (имзаны таркатып язу) (телефон)

20___ ел, «___» __________

___________________________________________